Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XIV-4**

Балык Бистәсе штп. 2021 елның 13 ноябре

2020 елның 13 мартындагы "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында" LII-2 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карарының үз көчен югалтуын тану турында

"Җир асты байлыклары турында" 1992 елның 21 февралендәге 2395-I номерлы Россия Федерациясе Законының 5 маддәсендәге 5 пунктының үз көчен югалтуын тану сәбәпле, "Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында "Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2021 елның 11 июнендәге 170-ФЗ номерлы Федераль законның 5 маддәсендәге 3 пункты нигезендә һәм муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 13 мартындагы "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында" LII-2 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

**2.** Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

И.Р. Таҗетдинов